| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**29.09.2022** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2560** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 976 номерлы карарына үзгәрешләр кертү

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешма хезмәткәрләренең бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакын тәртипкә салу максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 195 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 2 августындагы 751нче карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 976 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 20 августындагы 1557 номерлы, 2022 елның 17 декабрендәге 42 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән ) 5 пунктның 6 пунктчасындагы өченче абзацында «сәгатьле тариф ставкасының 7 проценты күләмендә» сүзләрен «хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән күләмдә» сүзләренә алмаштырырга; сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә
2. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru)

һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев